**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 43 03 октябрь 2016 ел.

Уразай авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Уразай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Уразай авылы башкарма комитетының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 16 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Уразай авыл җирлеге Советының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 42 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Уразай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 20 ноябрь 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   “Сез, Уразай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, I һәм II группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1)Урам утларынын төзеклэндерү, транспорт хезмэте, материаллар сатып алу,10 мең сум кулэмендэ,

2) Спорт корылмалары урнаштыру,105 мең сум күлэмендэ,

3) Уразай авылы юлларын ремонтлау (щебенка белэн каплау) өчен , 10 мең сум кулэмендэ,

ӘЙЕ ЮК

1. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
2. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: А.М.Шарифуллина